МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

_02.06.2017_ г.Казань № 172 _

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277нче боерыгы белән расланган кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, һәм сату буенча эшчәнлекне лицензияләү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Законнар белән яраштыруга китерү максатыннан әмер бирәм:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августында 289нчы әмере белән расланган кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату буенча лицензия эшчәнлеге буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2014 елның 8 августындагы 289нчы, 2015 елның 19 мартындагы 134нче, 2015 елның 3 июлендәге 317нче, 2016 елның 16 мартындагы 70нче, 2016 елның 2 июнендәге 176нчы әмерләре белән кертелгән үзгәрешләрне кертеп) (алда – Административ регламент).

2. Дәүләт информацион ресурслар һәм гаммәви мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлегенә (И.Сәгыйтов) әлеге үзгәрешләрне Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтына куюны тәэмин итәргә.

3. Әлеге әмернең үтәлешен контрольгә алуны министр урынбасары А.Д.Шәмсиевка йөкләргә.

Министр вазыйфасын башкаручы – беренче урынбасар,
Эшмәкәрлек үсеше департаменты
директоры Р.Р. Сибгатуллин

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
әмере белән расланган
__02.06.2017__ №__172__

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277нче әмере белән расланган кара металл, төсле металл әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшчәнлеген лицензияләү буенча Административ регламентка кертелә торган үзгәрешләр

Административ регламентның 1бүлегендә:

1.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.1. Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату буенча лицензияләү эшчәнлеге буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү (алда – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгеләү Административ регламенты (алда – Регламент).»;

1.5нче пунктның дүртенче абзацындагы «(1-3нче кушымталар)» сүзләрен «(1-2нче кушымталар) сүзләре белән алмаштырырга.»;

Административ регламентның 2нче бүлегендә:

2.1нче пунктның беренче абзацында «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату буенча эшчәнлекне лицензияләү ( алда – лицензия).»;

2.3нче пунктның беренче абзацында «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Лицензия, лицензиягә кушымта, лицензия дубликаты, лицензия күчермәсе, лицензия алырга теләүчегә (лицензиат) лицензия бирүдән (яңадан тутыру) баш тарту турында карар»;

2.3нче пунктның егерменче – егерме җиденче абзацларының «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«лицензия бирүче органның исеме;

Кушымтаның тәртип саны;

лицензиянең саны һәм датасы;

тулы һәм (булган очракта) кыскартылган исеме (шул исәптән фирма исеме), юридик затның оештыру-хокукый формасы, шәхси эшмәкәрнең исеме һәм (булган очракта) әтисенең исеме, аның шәхесен ачыклаучы документның исеме һәм реквизитлары;

юридик затның дәүләт теркәлү номеры (шәхси эшмәкәрнең);

салым түләүченең идентификацион номеры;

юридик затның урыны;

шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны;

эшчәнлек төренең лицензияләнгән составында алып барылган эш башкару урыны адресы;

вазифасы, Ф.И.О. һәм мөһер белән расланган вәкаләтле затның имзасы.»;

2.4нче пунктның икенче, өченче абзацларында «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Лицензияләрне яңадан эшләү (лицензияләнгән эшчәнлек төренә кергән башкарылучы эшләр исемлеге, юридик затлар яисә шәхси эшмәкәрләрнең лицензияләнгән эшчәнлек төренең урыны үзгәргән очракта) лицензияне яңадан эшләү турында гариза тутырып биргән көннән алып 30 көн эчендә башкарыла һәм аңа беркетелгән тулы күләмдә документлар да кертелә.

Лицензия (үзгәртү формасында юридик затны үзгәртеп корганда, аның исеме, эшләгән урыны үзгәргәндә, шулай ук шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны, исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, аның шәхесен ачыклаучы реквизитлары үзгәргән очракта (булганда), эшчәнлекнең лицензияләнгән төрен алып баруның аерым адреслары буенча эше туктатылганда) лицензияне һәм аңа беркетелгән документларны яңадан эшләү турында гариза бирелгән көннән алып 10 көн эчендә яңадан эшләү.»;

2.4нче пунктның бишенче абзацындагы «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«лицензияне туктату турында лицензиат гаризасын алган көннән алып 5 көн эчендә лицензияне гамәлдән туктату.»;

2.5нче пунктның 1нче пунктындагы өченче абзацта «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«б) соискательнең лицензияләнгән эшчәнлек алып баруын раслаган һәм җир участоклары, биналар, төзелешләр, корылмалар һәм биналарга милек хокукы биргән һәм Бердәм дәүләт милек реестрында теркәлгән документлар күчермәләре (әгәр дә андый хокуклар күрсәтелгән реестрда теркәлгән булса, шушы җир участоклары, биналар, корылмалар һәм төзелешләр турында белешмәләр бирелә);»;

2.5нче пунктның 2,3нче подпунктларының «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Лицензияне яңадан тутыру өчен (юридик затның яисә шәхси эшмәкәрнең лицензияләнгән эшчәнлек төрен алып бару урынының, лицензияләнгән эш төренә кергән башкарылучы эшләр исемлеге үзгәргән очракта):

а) лицензияне үзгәртү турында гариза ( Регламентка 2нче кушымта);

б) 1нче пунктның «б», «в», «г», «д» подпунктларында күрсәтелгән белешмәләр кертелгән документлар күчермәләре;

в) электрон имза куелган электрон документлар формасында лицензиянең яисә гамәлдәге лицензиянең оригиналы;

г) беркетелгән документларга опись.»;

3. Лицензияне үзгәртү өчен (үзгәрү формасында юридик затны реорганизацияләгәндә, аның исеме, торган урыны адресы үзгәргәндә, шулай ук шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны, исеме, фамилиясе, аның шәхесен ачыклаучы документ реквизитлары үзгәргәндә, лицензияләнгән эш төрен алып баруның аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылганда):

а) лицензияне үзгәртү турында гариза (Регламентка 2нче кушымта);

б) кәгазь формасында булган гамәлдәге лицензиянең оригиналы яисә электрон имза куелган электрон документ формасында лицензия;

в) беркетелгән документларга опись.»;

2.5нче пунктның 5нче подпунктындагы «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«5. Лицензияне гамәлдән туктату өчен:

а) лицензияне гамәлдән туктату турында гаризасы.»;

2.9нче пунктның 1нче подпунктындагы «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Лицензия бирүдән, лицензияне үзгәртүдән баш тарту өчен нигезләмәләр:

а) лицензия алырга теләүче (лицензиат) лицензия алу (үзгәртү) турында биргән гаризада һәм аңа беркетелгән документларда информациянең дөреслеккә туры килмәве;

б) лицензия алырга теләүченең (лицензиат) тикшерү барышында лицензион таләпләргә ярашмавы.»;

2.10нчы пунктында «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасыннан «лицензия срогын озайту - 750 сум» дигән сүзләрне алып ташларга;

2.15нче пунктта «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы күрсәткечләре булып тора:

документлар кабул итү һәм карау срокларын үтәү;

дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алу срогының үтәлеше;

дәүләт хезмәткәрләре кылган Регламентны бозуга прецедентлар булу (нигезле дәгъвалар).

Дәүләт хезмәтләренең күрсәтү дәрәҗәсенең күрсәткечләре булып тора:

Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын урында урнашканлыгы;

Гариза бирүчеләрдән документлар кабул итә торган белгечләрнең, биналарның кирәкле санда булуы;

Дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында төгәл мәгълүматның информацион стендларда, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында булуы;

Гаризаны электрон формада бирү мөмкинлеге;

Инвалидларга башка кешеләр белән беррәттән хезмәт алырга комачаулаган каршылыкларны җиңүдә ярдәм итү;

Дәүләт хезмәте күрсәтелүче инвалидларга биналарда мөмкинлекләр булу, инвалидлар өчен башкалар белән тигез хезмәт алу өчен комачаулаган биналарга бәйле булмаган башка төрле каршылыкларны җиңүдә ярдәм итү;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша электрон документлар формасында гариза һәм документлар биргәндә мөрәҗәгать итүченең хезмәтләрне Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында шәхси кабинет аша электрон формада алу мөмкинлеге бар (сатканда).

Дәүләт хезмәтләре алу турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алган вакытта бүлек белгече белән мөрәҗәгать итүче дүрт тапкыр аралашырга мөмкин (гариза бирү, документар тикшерү актына кул кую, чыгып тикшерү актына кул кую, лицензия алу). Аралашу озынлыгы Регламент белән билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче mert.tatarstan.ru сайтында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталында (электрон төрдә хезмәт күрсәтү турында гариза бирелгән очракта), МФЦда (МФЦ аша хезмәтләр алуга гариза бирелгән очракта) алырга була.»;

Административ регламентның 3нче бүлегендә:

3.1нче пунктның 3.1.2нче подпунктында «5» санын «4» санына алмаштырырга;

3.3нче пунктының 3.3.5нче подпунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.3.5. ведомствоара электрон аралашу системасы аша килгән запрослар нигезендә белгечләр поставщиклар мәгълүматлары буенча соралган документларны (информацияне) бирә яисә документлар булмавы турында уведомлениене һәм (яисә) дәүләт хезмәте өчен кирәкле информацияне җибәрә (алда – баш тарту турында уведомление).

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләр тарафыннан җибәрелгән запрослар нигезендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: документлар (белешмәләр) яисә Бүлеккә җибәрелгән баш тарту турында уведомление.»;

3.4нче пункттан «законнарда каралган очракта лицензия срогын озайту» сүзләрен алып ташларга;

3.5нче пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.5. Лицензияне үзгәртү (үзгәртеп кору формасында юридик затны реорганизацияләү очрагында, аның исеме, адресы һәм шулай ук шәхси эшмәкәрнең

яшәү урыны, исеме, фамилиясе, әтисенең исеме (әгәр булса), шәхесен ачыклаучы документ реквизитлары үзгәргән очракта, аерым адреслар буенча лицензияләнгән эшчәнлек төре алып барган урыннар туктатылганда)» каралган;

3.5нче пунктның 3.5.3нче подпунктының икенче абзацында «3» санын «2» саны белән алмаштырырга;

3.5нче пунктның 3.5.5нче подпунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.5.5. Мәгълүматлар белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон аралашу системасы аша алынган запрослар нигезендә соралган документларны (информацияне) бирә яисә документлар булмау турында уведомлениене һәм (яисә) дәүләт хезмәте өчен кирәкле информацияне җибәрә (алда – баш тарту турында уведомление).

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мәгълүматлар белән тәэмин итүче тарафыннан җибәрелгән запрослар нигезендә законда билгеләнгән срокларда башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән баш тарту турында документлар (белешмәләр) яисә уведомление.»;

3.7нче пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.7. Лицензияне гамәлдән чыгару

3.7.1. Лицензиянең гамәлдән чыгарылуы турында гаризаны лицензиат делопроизводство бүлегенә кәгазь формада яисә уведомление белән почта аша җибәрә яисә лицензиатның правоприемнигы федераль закон белән каралган затның квалификацияле көчәйтелгән электрон имзасы куелган электрон формада бирә ала.

3.7.2. Делопроизводство бүлеге белгече түбәндәгеләрне башкара:

Кабул итү, Электрон Хөкүмәттә лицензиянең гамәлдән чыгарылуы турында гаризаны теркәү;

Бүлеккә лицензиянең туктатылуы турында гариза бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар лицензиянең туктатылуы турында гариза кергән көннән гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: бүлеккә карауга җибәрелгән лицензияләрне гамәлдән чыгару турында теркәлгән гариза.

3.7.3. Бүлек белгече лицензиянең эштән туктатылуы турында әмер проектын әзерли һәм аны бүлек җитәкчесенә, идарә җитәкчесенә һәм юридик бүлек җитәкчесенә килешүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланган моменттан бер көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензияне эшеннән туктату турында әмер проекты, лицензиягә кушымталар.

ц.7.4. Бүлек җитәкчесе, идарә җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе лиценцияне эштән туктату турында әмер проектын килештерәләр һәм ул министрга имзага җибәрелә (министр урынбасарына).

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар моннан элекке процедуралар тәмамланган моменттан бер көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: министрга (министр урынбасарына) имзага җибәрелгән лицензияне эшеннән туктату турында әмернең килешенгән проекты.

3.7.5. Министр (министр урынбасары) лицензияне эшеннән туктату турында әмергә кул куя һәм бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар моннан элекке процедуралар тәмамланган моменттан бер көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензиянең эштән туктатылуы турында кул куелган әмер.

3.7.6. Бүлек белгече лицензиянең эштән туктатылуы турында кул куелган әмер нигезендә лицензиянең эштән туктатылуы турында белешмәләрне, лицензиягә кушымталарны лицензияләр реестрына кертә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура лицензиянең эштән туктатылуы турында әмергә кул куелган көннән үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: лицензияләрнең актуальләштерелгән реестры.

3.7.7. Бүлек белгече лицензиатка лицензиянең эштән туктатылуы турында язма уведомление җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура Регламентның 3.7.5нче пункты белән каралган процедуралар тәмамланган моменттан бер көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: лицензиянең эштән туктатылуы турында уведомление.

Әгәр лицензиянең эштән туктатылуы турында гариза электрон формада бирелгән булса, уведомление лицензияләгән органның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән җибәрелә.»;

3.10нчы пунктның 3.10.1 подпунктының икенче абзацында «4» санын «3» саны белән алмаштырырга;

Административ регламентның 4нче бүлегендә:

4.3нче пункт «Тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерүләр Министрлыкның планлы тикшерүләрен уздыру еллык планы нигезендә алып барыла. Планнан тыш тикшерүләр – Министрлык күрсәтмәсе буенча.» абзаөын алып ташларга;

4.4, 4.5нче пунктларны шуларга ярашлы 4.3, 4.4 дип исәпләргә;

Административ регламентка 1,2нче кушымталарны яңа редакциядә бирергә:

«Кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү буенча лицензияләнгән эшчәнлек буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентына 1нче кушымта

ГАРИЗА

Кара металл, төсле металл ватыгын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сатуга лицензия бирү турында

Бирүегезне сорыйм ______________________________________________

(тулы һәм кыскартылган исеме(булганда) , шул исәптән фирма исеме, һәм оештыру-хокукый формасы – юридик зат өчен; фамилиясе, исеме, отчествосы, шәхесен ачыклаучы документы, – шәхси эшмкәр өчен)

Кара металл, төсле металл әзерләүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга лицензия
Эш төре - ________________________________________________________________
(лицензияләнгән эшчәнлек төре составына кертелгән эш төре исемен күрсәтергә)

Юридик затның урнашкан урыны (шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны адресы) ____________________________________________________________________

Язышу өчен адрес_________________________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, контакт телефоны)

Лицензияләнгән эшчәнлек төре алып барылган урыннар адресы_______________________

Дәүләт теркәве турында төп дәүләт теркәве номеры ____________________________________________________________________
(ОГРН – юридик зат өчен, ОГРНИП – шәхси эшмәкәр өчен)

Дәүләт теркәве алып барган орган урнашкан урын адресын күрсәтеп, юридик затның (шәхси эшмәкәрнең) бердәм дәүләт реестрына керү фактын раслаган документлар_______________________________________________________________

Салым түләүченең Идентификацион номеры (ИНН)______________________________

Юридик затны (шәхси эшмәкәрне) салым органында исәпкә кую фактын раслаган документлар________________________________________________________________

Лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасын түләү фактын раслаган яисә күрсәтелгән дәүләт пошлинасын түләү фактын раслаган башка белешмәләр документларының реквизитлары_____________________________________________________________

Лицензия эшчәнлеге алып бару өчен кирәкле һәм юридик затның (шәхси эшмәкәрнең) милек хокукында яисә милке Бердәм дәүләт реестрында теркәлгән закон нигезендә башка хокукын раслаган җир участоклары, биналар, төзелешләр, корылмалар һәм биналар турында (биналарның, төзелешләрнең, корылмалар һәм биналарның бердәм аерылган өлеше) белешмәләр_______________________________________________________________
Лицензияләү мәсьәләләре буенча вәкаләтле хезмәткәр___________________________
(вазифасының исеме, Ф.И.О., телефон)

Юридик зат җитәкчесе
(шәхси эшмәкәр) ________________ ________________
(имза, мөһер) (ФИО)

Искәрмә. Мөһер - булган очракта Язма формада соратып алган көннән алып аңа кул куйганга кадәр шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм (шәхси эшмәкәрләр өчен) ________________________
(Ф.И.О., имза)

2нче кушымта
Кара металл, төсле металл әзерләгән, саклаган, эшкәрткән һәм сату буенча лицензияләнгән эшчәнлек буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү Административ регламентына

## ГАРИЗА
### лицензияне яңадан эшләү турында

(юридик зат яисә шәхси эшмәкәр алып барган лицензияләнгән эшчәнлек алып барган урын адресы, лицензияләнгән эшчәнлек төренә кергән башкарылган эшләр исемлегендә үзгәрешләр булганда, яңарыш формасында юридик зат реорганизацияләнгәндә, исеме үзгәргәндә, шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны, исеме, фамилиясе (булса) отчествосы, шәхесен ачыклаучы документлар реквизитлары үзгәргәндә, лицензия эшчәнлеге алып барган урыннарның аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылганда)

Яңадан эшләвегезне сорыйм____________________________________________________
(тулы һәм кыскартылган исеме(булганда), шул исәптән фирма исеме, һәм оештыру-хокукый формасы – юридик зат өчен; фамилиясе, исеме, отчествосы, шәхесен ачыклаучы документы, – шәхси эшмкәр өчен)
лицензияне (тулы һәм (булганда) кыскартылган исеме, шул исәптән фирма исеме һәм ____________________________________________________________________
( лицензиянең номеры һәм датасы, лицензияләнгән эшчәнлек төре)

Эш төре - ___________________________________________________________________
(лицензияләнгән эшчәнлек төре составында башкарылган эш төренең исемен күрсәтергә)
бәйле ______________________________________________________________________

Юридик затның торган урыны (шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны адресы) ____________________________________________________________________________

Язышу өчен адрес ________________________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, контакт телефоны)
Эшчәнлек алып барган орган урнашкан урын адресын күрсәтеп, юридик затның (шәхси эшмәкәрнең) бердәм дәүләт реестрына керү фактын раслаган документлар_____________________________________________________________
Лицензияләнгән эшчәнлек төре алып барылган урыннар адресы_________________

Дәүләт теркәве турында төп дәүләт теркәве номеры ____________________________________________________________________________
(ОГРН – юридик зат өчен, ОГРНИП – шәхси эшмәкәр өчен)

Дәүләт теркәве алып барган орган урнашкан урын адресын күрсәтеп, юридик затның (шәхси эшмәкәрнең) бердәм дәүләт реестрына керү фактын раслаган документлар_____________________________________________________________

Салым түләүченең Идентификацион номеры (ИНН)_____________________________

Юридик затны (шәхси эшмәкәрне) салым органында исәпкә кую фактын раслаган документлар______________________________________________________________

Лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасын түләү фактын раслаган яисә күрсәтелгән дәүләт пошлинасын түләү фактын раслаган башка белешмәләр документларының реквизитлары___________________________________________________________

Лицензия эшчәнлеге алып бару өчен кирәкле һәм юридик затның (шәхси эшмәкәрнең) милек хокукында яисә милке Бердәм дәүләт реестрында теркәлгән закон нигезендә башка хокукын раслаган җир участоклары, биналар, төзелешләр, корылмалар һәм биналар турында (биналарның, төзелешләрнең, корылмалар һәм биналарның бердәм аерылган өлеше) белешмәләр____________________________________________________________
Лицензияләү мәсьәләләре буенча вәкаләтле хезмәткәр__________________________
(вазифасының исеме, Ф.И.О., телефон)
Юридик зат җитәкчесе
(шәхси эшмәкәр) ________________ ________________
, мөһер) (ФИО)
Искәрмә. Мөһер - булган очракта. Язма формада соратып алган көннән алып аңа кул куйганга кадәр шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм (шәхси эшмәкәрләр өчен) ____________
(Ф.И.О., имза)

Административ регламенттан 3нче кушымтаны алып ташларга;

4,5нче кушымталарны Административ регламентка ярашлы рәвештә 3,4нче кушымталар дип исәпләргә.